| | | |
|---|---|---|
| Килешенде:<br>Татарстан Республикасы<br>Яр Чаллы шәһәре<br>Мәгариф идарәсе<br>башлыгы<br>____________<br>Р.Н.Хузин | Татарстан<br>Язучылары берлеге<br>урынбасары<br>Язучыларның Чаллы<br>бүлеге җитәкчесе<br>____________<br>Ф.М.Сафин | Раслыйм:<br>Муниципаль автономияле<br>гомуми белем бирү<br>учреждениесе “21 нче гомуми<br>урта белем бирү мәктәбе”<br>директоры<br>____________<br>И.А.Хабибуллин |

Яр Чаллы шәһәре язучылары һәм шагыйрьләре иҗатына багышланган
I төбәкара фәнни-гамәли конференция

# нигезләмәсе.

## I. Гомуми мәгълүмат

1.1. Нигезләмә Яр Чаллы шәһәре язучылары һәм шагыйрьләре иҗатына багышланган I төбәкара фәнни-гамәли конференция (алга таба - Конференция) үткәрү максатын, бурычларын, тәртибен билгели. Конференцияне үткәрү тәртибе, алымнары үзгәрергә мөмкин.

**Искәрмә**: *Конференция дистанцион формада үтәргә мөмкин.*

1.2. Конференция балалар бакчалары тәрбиячеләрен, мәктәп китапханәләренең педагог-китапханәчеләрен, гимназияләр, лицейлар, гомуми белем бирү оешмаларында туган (татар) тел һәм әдәбиятыннан башлангыч, төп һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә куючы педагогларны берләштерә.

## II.Конференциянең максаты һәм бурычлары

2.1. Туган (татар) тел һәм әдәбияты укытучыларын һәм укучыларны, тәрбиячеләрне, педагог-китапханәчеләрен фәнни-эзләнү эшләренә тарту, интеллектуаль сәләтләрен һәм иҗади фикерләвен активлаштыру.

2.2. Бурычлары:

- Яр Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итүче, шулай ук Яр Чаллы шәһәреннән чыккан хәзерге вакытта башка шәһәрләрдә яшәүче язучылар һәм шагыйрьләрне барлау, иҗатларын өйрәнү һәм укучыларны аларның иҗаты белән таныштыру;
- укучыларда телебезгә, милли гореф-гадәтләребезгә, рухи байлыгыбызга мәхәббәт тәрбияләү;
- туган телгә һәм әдәбиятка, сәнгатькә, милли традицияләргә мәхәббәт тәрбияләү;
- тикшеренү коллективлары белән иҗади мөнәсәбәтләр формалаштыру, бергәләп тере аралашуны оештыру;
- хәзерге укучыларның гомуми һәм коммуникатив культурасын, социаль адаптациясен һәм гражданлык активлыгын үстерү;
- фәнни эзләнүләрдә иҗадилыкка омтылыш һәм кызыксыну тәрбияләү;
- татар халкының мәдәни-тарихи мирасын, туган як табигатен өйрәнүгә кызыксыну уяту;
- сәләтле балаларны ачыклау һәм аларның үсеше өчен шартлар тудыру;

- укытучыларның алдынгы тәҗрибәсен барлау, эзләнү эшенә тартып, аларны фәнни эшләргә җәлеп итү;

- республиканың төп һәм урта гомуми белем бирү мәктәпләре, гимназия, укытучыларының һөнәри үсеш юлларын билгеләү, педагогик тәҗрибәне тарату.

## III.Конференцияне оештыручылар

3.1. Конференцияне оештыручылар:

- Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының мәгариф идарәсе;
- Татарстан Язучылары берлеге, Язучыларның Чаллы бүлеге;
- Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет учреждениесе "Мәгълүмати-методик үзәк»;
- Яр Чаллы шәһәренең муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе "21 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе".

## IV.Конференциядә катнашучылар

4.1. Конференциядә гомуми белем бирү оешмаларының 7-11 сыйныф укучылары, гимназияләр, лицейлар, башлангыч сыйныф укытучылары, төп, урта гомуми белем бирү мәктәпләренең туган тел һәм әдәбияты укытучылары, балалар бакчалары тәрбиячеләре, мәктәп китапханәләренең педагог-китапханәчеләре катнаша ала.

## V.Конференциянең эш юнәлешләре

5.1. Яр Чаллы шәһәре язучылары һәм шагыйрьләре иҗатына багышланган I төбәкара фәнни-гамәли конференция:

Беренче юнәлеш: Яр Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итүче язучылар һәм шагыйрьләр иҗаты (*Факил Сафин, Айдар Хәлим, Фәүзия Бәйрәмова, Айрат Суфиянов, Мансур Сафин, Галиәхмәт Шаһи, Рәшит Бәшәр, Марс Янудин, Сирень Якупова, Булат Сәлахов, Данис Хәйруллин, Әлфия Ситдыйкова, Рәзинә Мөхияр, Әнвәр Шәрипов, Рәкит Аллабирде, Земфира Исламова, Лилия Фәттахова, Рафис Сәлимҗанов, Зөләйха Минһаҗева, Хәмит Латыйпов, Айгөл Әхмәтгалиева, Фидаил Мәҗитов, Лилия Гыйбадуллина; Кадыйр Сибгатуллин, Рахмай Хисмәтуллин, Ямаш Игәнәй, Хәниф Хөснуллин, Ягъсуф Шәфиков, Фаяз Дунай һ.б.*);

Икенче юнәлеш: Яр Чаллы шәһәреннән чыккан, хәзерге вакытта башка шәһәрләрдә яшәүче һәм яшәгән язучылар һәм шагыйрьләр иҗаты (*Вахит Имамов, Разил Вәлиев, Мөдәррис Әгъләм, Рахман Шәфигуллин, Амур Фәлах, Тәлгать Галиуллин, Равил Сабыр, Фирүзә Җамалетдинова һ.б.*).

## VI. Фәнни-гамәли хезмәтләргә таләпләр

6.1. Фәнни-гамәли хезмәтләр түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

- чыгыш ясаучының теманы ачып бирә алуы;
- аргументлаштырылган һәм иҗади фикерләү сәләтенә ия булуы;
- грамоталы, әдәби телдә язылган булуы, мисал итеп китерелгән фактларның дөрес булуы шарт;
- хезмәтләрне күрсәтмә материаллар, презентацияләр белән баету;
- куелган проблема буенча әдәбият, чыганакларны куллану, эшләрдә сылтамалар дөрес куелу.

6.2.Фәнни-гамәли хезмәтләр, чыгышлар бары тик татар телендә генә кабул ителә.

6.3. Хезмәтнең язылу тәртибе.

Текстның күләме 8 басма биттән артмаска тиеш. Тикшеренү эшенең кушымтасы рәсемнәр, схемалар һәм карталар, фотолар, кушымта күләме 5 бит булырга мөмкин. Эш төзәтүләрсез, А4 форматында (шрифт Times New Roman-14, интервал 1,5, уңнан-1,5; сулдан-2,5 астан-2; өстән-1,5) компьютерда басылган булырга тиеш. Эзләнү эшләре папкага тегелеп тапшырыла һәм кире кайтарылмый.

Титул битенә белем бирү учреждениесенең тулы исеме, катнашучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, сыйныфы, тема, эшнең юнәлеше һәм җитәкчесенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме языла.

Кереш, йомгак, әдәбият исемлеге, төп өлешнең аерым бүлекләре яңа биттән башлана.

Кулланылган әдәбият исемлеге яңа юлдан алфавит тәртибендә языла.

**Республикакүләм башка конкурсларда катнашып призлы урын алган, матбугатта басылган эшләр кабул ителми.**

6.3. **<u>Чыгыш регламенты</u>** һәм бәяләү критерийлары.

Жюри әгъзалары укучыларның һәм укытучыларның тикшеренү эшләрен түбәндәге критерийлар буенча бәялиләр:

- проблеманы ачу тирәнлеге, бөтенлек, махсус техника һәм техниканы куллану;
- дөрес логикага буйсынган һәм исбатлау өлеше булган көчле аргументлар һәм нәтиҗәләр күрсәтү; фәнни эш; эш максатларын дөрес билгеләү;
- чыгышның композицион төгәллеге, үз фикереңне раслый белү, теманы ачу дәрәҗәсе;
- тәкъдим ителгән эшнең хәзерге заман шартларына туры килүе, күрсәтмә материалның булуы;
- аралашу һәм сөйләм культурасы.

Чыгышларның озынлыгы 5-7 минут. Чыгыш вакытында укучы төп уйларны һәм нәтиҗәләрне кыскача һәм ачык итеп күрсәтергә тиеш. Компьютер презентациясе хуплана.

Эшләр электрон һәм кәгазь вариантта кабул ителә (икенче турга узучылар кәгазь вариантын алып киләләр).

## VII. Конференцияне үткәрү тәртибе

7.1. Оештыру комитеты конференциядә катнашу өчен гаризаларны сайлап алу хокукын үзендә калдыра.

7.2. Конференция Яр Чаллы шәһәренең муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе “21 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”ндә үткәрелә.

7.3. Конференция 2 этапта үткәрелә:

I этап – сайлап алу этабы. Катнашу өчен заявка, фәнни-гамәли эшләрне, тезисларны, түләү квитанцияләрен 2023 нче елның 13 февраленә кадәр **<u>dgauhar75@mail.ru</u>** электрон адресына җибәрергә.

II этапка узучылар исемлеге 2023 нче елның 20 февралендә Яр Чаллы шәһәренең муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе “21 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”нең официаль сайтына эленә.

II этап – йомгаклау этабы. Икенче турга узучылар 2023 нче елның 25 февралендә Яр Чаллы шәһәренең муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе “21 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”нә чакырыла. Конференция 9.00.сәгатьтә башлана.

Эшләренең кәгазь варианты чыгыш ясар алдыннан экспертлар комиссиясенә тапшырыла.

Элемтәгә керү өчен кәрәзле телефон: 89872389640 (МБ җитәкчесе Демухаметова Гәүһәр Фаяз кызы)

7.4. Конференциядә катнашу өчен, гариза-заявка түбәндәге формада җибәрелә: *кушымта №1*.

7.5. Конференциядә катнашу өчен 150 сум күләмендә (һәр эш өчен) оештыру взносы түләргә кирәк. Квитанция копияләрен гариза-заявка,эшләр белән бергә җибәрү сорала. Оештыру взносы дипломнар, сертификатлар, оештыру эшләре өчен тотыла: *кушымта №2*

## VIII. Конференцияне йомгаклау һәм нәтиҗә ясау

Республикакүләм фәнни-тикшеренү конференциядә катнашучыларның чыгышы алдан билгеләнгән критерийлар буенча бәяләнә.

Катнашучыларның чыгышларын тыңлап бетергәннән соң, эксперт комиссиясе утырышы үткәрелә һәм җиңүчеләр турында карар чыгарыла.

Эксперт комиссиясенең карары протоколлаштырыла, үзгәрешләр кертелми.

Фәнни-гамәли конференциядә җиңүчеләргә дипломнар, сертификатлар, рәхмәт хатлары тапшырыла, дистанцион формада үткәрелсә һәм икенче турга узмаучыларга 10 нчы марттан соң гаризада күрсәтелгән электрон адреска җибәрелә.

*Кушымта №1 (Анкетаны бары татарча тутырырга!!!)*

| АНКЕТА | |
|---|---|
| Эшнең темасы | |
| Юнәлеш | |
| Катнашучының фамилиясе, исеме, этисенең исеме (тулысынча) | |
| укытучылар өчен - фәнни дәрәҗәсе, квалификацион категориясе<br>укучылар өчен – сыйныф, җитәкченең фамилиясе, исеме, этисенең исеме | |
| Оешма исеме (устав буенча), адресы, телефоны | |
| Катнашучының телефоны электрон адресы<br>(Укучы өчен фәнни җитәкче үз телефон номерын яза) | |

*Кушымта №2*

РЕКВИЗИТЫ

| | |
|---|---|
| Полное наименование организации | муниципальное автономное общеобразовательное учреждение города Набережные Челны «Средняя общеобразовательная школа № 21» |
| Краткое наименование организации | МАОУ «СОШ № 21» |
| Юридический адрес, фактический адрес | РТ, г. Набережные Челны, ул. Железнодорожников д. 65 |
| ИНН/КПП | 1650083359/165001001 |
| Расчетный счет | 03234643927300001100 |
| л/с | ЛАВ30800070-СОШ21 |
| Наименование банка | ОТДЕЛЕНИЕ-НБ РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БАНКА РОССИИ//УФК по Республики Татарстан г.Казань |
| Корреспондентский счет | 40102810445370000079 |
| БИК | 019205400 |